ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 10 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2023 елның 23 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2205-VI ДС

Проект

Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты–
Татарстан Республикасы
Рәисе

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

### 1 статья

1. 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 383 929 489,4 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 383 929 489,4 мең сум итеп.

2. 2025 елга һәм 2026 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2025 елга 387 195 794,7 мең сум һәм 2026 елга 412 453 816,0 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2025елга 399 693 755,0 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 12 650 000,0 мең сум, һәм 2026 елга 431 325 559,3 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 21 000 000,0 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 2025 елга 12 497 960,3 мең сум һәм 2026 елга 18 871 743,3 мең сум итеп.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2025 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 107 714 047,3 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы күләмендә расларга.

2. 2026 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 99 078 719,7 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы күләмендә расларга.

3. 2027 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 89 488 992,3 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 7 298 707,5 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 7 298 707,5 мең япон иенасы күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 елга 6 192 920,5 мең сум, 2025 елга 5 798 328,5 мең сум һәм 2026 елга 5 798 328,5 мең сум күләмендә расларга.

5. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. 2024 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыру өчен бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукын бирергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^{1}$ статьясындагы 2 пункты нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәрен әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарындагы дәүләт мәнфәгатьләре вәкилләре, 2023 ел

нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2024 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табыштан кимендә 30 процент күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2023 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2024 елның 1 июленә кадәр әлеге табыштан 30 процент күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 елга 5 710 293,1 мең сум, 2025 елга 5 940 000,3 мең сум һәм 2026 елга 6 179 010,8 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2024 елда үзгәрешләр кертү өчен әлеге статьяда расланган,

бюджетлар чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендәге «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча каралган бюджет ассигнованиеләре составындагы резервланган акчаларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча түбәндәгечә бүлү нигез булып тора дип билгеләргә:

1) оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә 2024 елга 3 720 646,6 мең сум, 2025 елга 3 794 238,8 мең сум, 2026 елга 3 899 197,6 мең сум күләмендә;

2) бюджет өлкәсе учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга 2024 елга 11 110 696,6 мең сум, 2025 елга 11 555 124,4 мең сум, 2026 елга 12 017 329,4 мең сум күләмендә;

3) аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга 2024 елга 2 647 577,6 мең сум, 2025 елга 2 753 480,7 мең сум, 2026 елга 2 863 619,9 мең сум күләмендә;

4) гражданнарның ихтыярый салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын башкаруга 2024 елга 1 352 100,0 мең сум, 2025 елга 1 352 100,0 мең сум, 2026 елга 1 352 100,0 мең сум күләмендә;

5) дәүләт (муниципаль) бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренә (эшләр башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 2 950 000,0 мең сум, 2025 елга 2 950 000,0 мең сум, 2026 елга 2 950 000,0 мең сум күләмендә.

**8 статья**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 2 һәм 7 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүче юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга, субсидия рәвешендәге грантлар – юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр – Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре булып тормаган коммерциягә карамаган оешмаларга, субсидия рәвешендәге грантлар – казна

учреждениесе булып тормаган коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**9 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2024 елда, 2025 һәм 2026 еллар план чорында җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен финанс хисабы елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2024 елда – 3 процентын, 2025 елда – 5 процентын, 2026 елда 5 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

**10 статья**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга – 21 914 025,3 мең сум;

2) 2025 елга – 23 605 574,3 мең сум;

3) 2026 елга – 24 957 341,0 мең сум.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2024 елда 20 628 732,9 мең сум, 2025 елда 22 151 002,7 мең сум, 2026 елда 23 763 082,1 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырырга.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие

буларак кулланыла торган күрсәткечне: 2024 елга – 2,264, 2025 елга – 2,264, 2026 елга – 2,264 итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләрне исәпләгәндә кулланыла торган әлеге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкару буенча шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен түбәндәгечә билгеләргә:

1) шәһәр җирлекләре буенча: 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 644,1 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 671,2 сум, 2026 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 423,6 сум;

2) авыл җирлекләре буенча: 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 265,9 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 266,9 сум, 2026 елга – бер кешегә исәпләгәндә 245,1 сум.

**Статья 11**

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 11 – 37 кушымталар нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга конкурс нигезендә муниципаль берәмлекләр арасында бүленә торган субсидияләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрне һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фонды исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

**12 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләү өчен җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 19 196 011,7 мең сум, 2025 елга 20 741 410,3 мең сум, 2026 елга 21 980 288,6 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2024 елга 10 002 880,7 мең сум, 2025 елга 10 143 269,8 мең сум, 2026 елга 10 394 665,3 мең сум, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасында билгеләнмәгән медицина ярдәменең өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 1 937 252,5 мең сум, 2025 елга 1 967 270,8 мең сум, 2026 елга 1 998 723,7 мең сум күләмендә;

2) «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән очракларда чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 8 065 628,2 мең сум, 2025 елга 8 175 999,0 мең сум, 2026 елга 8 395 941,6 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

**13 статья**

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 51 654 762,8 мең сум, 2025 елга 29 327 662,5 мең сум, 2026 елга 29 512 150,2 мең сум һәм аларны тиешенчә 2024, 2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

**14 статья**

Инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган акчаларның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2024 елга – 100 000,0 мең сум;
2) 2025 елга – 100 000,0 мең сум;
3) 2026 елга – 100 000,0 мең сум.

**15 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз, моңа Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирелүгә бәйле шундый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирле үзидарә органнарына 2024 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

**16 статья**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җирле бюджетларны финанслашу (аларны финанс белән тәэмин итү) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган мондый бюджетара трансфертларны җирле бюджетлар акчаларын алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләтләрен тапшыру турында карарларны Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара трансфертлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланa.

**17 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 38 кушымта нигезендә исәпкә алырга:

1) федераль бюджеттан 2024 елда 51 641 116,3 мең сум, 2025 елда 38 655 326,1 мең сум, 2026 елда 47 678 981,3 мең сум күләмендә;

2) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясеннән 2024 елда 87 198,1 мең сум күләмендә.

**18 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**19 статья**

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары буенча түләү өчен бирелгән, шушы контрактлар шартлары нигезендә 2023 елда түләнергә тиешле файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2023 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый бюджетара трансфертларны бирүгә бюджет ассигнованиеләренең, финанс белән тәэмин итү чыганагы юридик затларга субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2023 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый субсидияләрне бирүгә бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасыннан артмаган күләмдәге Татарстан Республикасы бюджетының 2024 елның 1 гыйнварына калган акчалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2024 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет

ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**20 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, суд эшчәнлеге турындагы, үтәтү эшен алып бару эшчәнлеге хакындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^8$ статьясындагы 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычны җайга салу шартларын билгели торган, акчалата йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору яисә аларны өлешләп түләү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү хакында ризалык килешүләре төзергә хокуклы.

**21 статья**

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны ирекле рәвештә каплаганда түләнә торган түләүләрдән Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының табигатьне саклау чаралары планы нигезендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм бәяләүгә һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыруга, хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану һәм аларны яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга җибәрелә дип билгеләргә.

**22 статья**

2024 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацының (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 **(**I өлеш**);** 2023, № 3 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әлмәт муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш;

4) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш.

**23 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

1 нче таблица

## 2024 елга
## Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 6 192 920,5 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | -16 111 859,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары | -16 111 859,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары җәлеп итү | 31 994 124,1 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар җәлеп итү | 31 994 124,1 |
| 01 03 01 00 02 0002 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар җәлеп итү (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга бирелгән бюджет кредитлары) | 31 994 124,1 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -48 105 983,3 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау | -48 105 983,3 |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары | -87 066,0 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| | бюджетларына бирелгән бюджет кредитлары, бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә, Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән бюджет кредитларыннан, махсус казначылык кредитларыннан тыш), | |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | шул исәптән: | |
| | федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрүнең өстәмә шартлары һәм тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 18 декабрендәге 1325 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауга юнәлдерелә торган акчалар | -87 066,0 |
| 01 03 01 00 02 0002 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга бирелгән бюджет кредитлары) | -31 994 124,1 |
| 01 03 01 00 02 2700 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән бюджет кредитлары) | -1 020 218,7 |
| 01 03 01 00 02 5600 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе дәүләт программаларының, илкүләм проектлар (программалар) составына керүче федераль проектларның, магистраль инфраструктураны модернизацияләүнең һәм киңәйтүнең комплекслы планының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган чараларны гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектларының | -15 004 574,5 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| | чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бюджет кредитлары) | |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 16 111 859,2 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -422 116 534,0 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -422 116 534,0 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -422 116 534,0 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -422 116 534,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 438 228 393,2 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 438 228 393,2 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 438 228 393,2 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 438 228 393,2 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 6 192 920,5 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалар) | 6 192 920,5 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларны) кире кайтару | 6 192 920,5 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларны) кире кайтару | 6 192 920,5 |
| 02 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын тышкы финанслау чыганаклары | -6 192 920,5 |
| 02 04 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын тышкы финанслауның башка чыганаклары | -6 192 920,5 |
| 02 04 01 00 00 0000 000 | Чит ил валютасында дәүләт гарантияләре | -6 192 920,5 |
| 02 04 01 00 00 0000 800 | Дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта йә принципалга карата бенефициар таләбе хокукларын гарантка бирүгә бәйле булса, дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -6 192 920,5 |
| 02 04 01 00 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъектының дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта йә принципалга карата бенефициар таләбе хокукларын гарантка бирүгә бәйле булса, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -6 192 920,5 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| Барлык чыганаклар | | 0,0 |

2 нче таблица

## 2025 һәм 2026 еллар план чорына
## Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын
## финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел |
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 18 296 288,8 | 24 259 741,6 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | -8 635 327,6 | -9 589 727,5 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары | -8 635 327,6 | -9 589 727,5 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары җәлеп итү | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар җәлеп итү | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| 01 03 01 00 02 0002 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар җәлеп итү (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга бирелгән бюджет кредитлары) | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -40 901 643,8 | -43 960 878,8 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау | -40 901 643,8 | -43 960 878,8 |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан | -6 873 102,3 | -7 827 502,2 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел |
| | Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бирелгән бюджет кредитлары, бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә, Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән бюджет кредитларыннан, махсус казначылык кредитларыннан тыш), | | |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | шул исәптән: | | |
| | федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрүнең өстәмә шартлары һәм тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 18 декабрендәге 1325 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауга юнәлдерелә торган акчалар | -6 694 977,9 | -6 694 977,9 |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауга юнәлдерелә торган акчалар | 0,0 | -802 360,0 |
| 01 03 01 00 02 0001 810 | федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «2021 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе | -178 124,4 | -330 164,3 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел |
| | Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычны каплауга юнәлдерелә торган акчалар | | |
| 01 03 01 00 02 0002 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга бирелгән бюджет кредитлары) | -32 266 316,2 | -34 371 151,3 |
| 01 03 01 00 02 2700 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән бюджет кредитлары) | -1 020 218,7 | -1 020 218,7 |
| 01 03 01 00 02 5700 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау (махсус казначылык кредитлары) | -742 006,6 | -742 006,6 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 18 630 093,2 | 25 958 276,1 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -427 763 634,1 | -454 716 160,3 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -427 763 634,1 | -454 716 160,3 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -427 763 634,1 | -454 716 160,3 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -427 763 634,1 | -454 716 160,3 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 446 393 727,3 | 480 674 436,4 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын | 446 393 727,3 | 480 674 436,4 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел |
| | киметү | | |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 446 393 727,3 | 480 674 436,4 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 446 393 727,3 | 480 674 436,4 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 8 301 523,2 | 7 891 193,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 2 503 194,7 | 2 503 194,7 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 2 503 194,7 | 2 503 194,7 |
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 2 503 194,7 | 2 503 194,7 |
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 2 503 194,7 | 2 503 194,7 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалар) | 5 798 328,5 | 5 387 998,3 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларны) кире кайтару | 5 798 328,5 | 5 387 998,3 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларны) кире кайтару | 5 798 328,5 | 5 387 998,3 |
| 02 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын тышкы финанслау чыганаклары | -5 798 328,5 | -5 387 998,3 |
| 02 04 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын тышкы финанслауның башка чыганаклары | -5 798 328,5 | -5 387 998,3 |
| 02 04 01 00 00 0000 000 | Чит ил валютасында дәүләт гарантияләре | -5 798 328,5 | -5 387 998,3 |
| 02 04 01 00 00 0000 800 | Дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта йә принципалга карата бенефициар таләбе хокукларын гарантка бирүгә бәйле булса, дәүләт гарантияләрен чит ил | -5 798 328,5 | -5 387 998,3 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел |
| | валютасында үтәү | | |
| 02 04 01 00 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъектының дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта йә принципалга карата бенефициар таләбе хокукларын гарантка бирүгә бәйле булса, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -5 798 328,5 | -5 387 998,3 |
| Барлык чыганаклар | | 12 497 960,3 | 18 871 743,3 |

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

1 нче таблица

### 2024 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары

(мең сумнарда)

| | Суммасы |
|---|---|
| Эчке дәүләт хисаплашулары | |
| акчалар җәлеп итү күләмнәре | 31 994 124,1 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 48 105 983,3 |
| шул исәптән: | |
| бюджет кредитлары | |
| акчалар җәлеп итү күләмнәре | 31 994 124,1 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 48 105 983,3 |
| шул исәптән | |
| федераль бюджеттан бюджет кредитлары, бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә, Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән бюджет кредитларыннан, махсус казначылык кредитларыннан тыш | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 87 066,0 |
| бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга федераль бюджеттан 2024 елның 28 декабреннән дә соңга калмыйча каплау срогы белән бирелгән бюджет кредиты | |
| акчалар җәлеп итү күләмнәре | 31 994 124,1 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 31 994 124,1 |
| Россия Федерациясе дәүләт программаларының, илкүләм проектлар (программалар) составына керүче федераль проектларның, магистраль инфраструктураны модернизацияләүнең һәм киңәйтүнең комплекслы планының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган чараларны гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга федераль бюджеттан 2024 елның 27 апреленнән дә соңга калмыйча каплау срогы | |

| | Суммасы |
|---|---|
| белән бирелгән бюджет кредитлары | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 15 004 574,5 |
| инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бюджет кредиты | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 1 020 218,7 |

2 нче таблица

## 2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары

(мең сумнарда)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел |
| Эчке дәүләт хисаплашулары | | |
| акчалар җәлеп итү күләмнәре | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 40 901 643,8 | 43 960 878,8 |
| шул исәптән: | | |
| бюджет кредитлары | | |
| акчалар җәлеп итү күләмнәре | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 40 901 643,8 | 43 960 878,8 |
| шул исәптән | | |
| федераль бюджеттан бюджет кредитлары, бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә, Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен алдан финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән бюджет кредитларыннан, махсус казначылык кредитларыннан тыш | | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 6 873 102,3 | 7 827 502,2 |
| бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга федераль бюджеттан тиешле елның соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча каплау срогы белән бирелгән бюджет кредиты | | |
| акчалар җәлеп итү күләме | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 32 266 316,2 | 34 371 151,3 |
| инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бюджет кредиты | | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләмнәре | 1 020 218,7 | 1 020 218,7 |
| федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча ирекле акчалары хисабына бюджет кредиты (махсус казначылык кредиты) | | |
| йөкләмәләрне каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 742 006,6 | 742 006,6 |

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

1 нче таблица

## 2024 елга
## Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(тыс. рублей)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 332 079 393,6 |
| Табышка, керемнәргә салымнар | 1 01 00000 00 0000 000 | 209 268 420,2 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 112 821 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 96 447 420,2 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 41 439 668,5 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 41 439 668,5 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 17 285 198,0 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 15 939 098,0 |
| Һөнәри керемгә салым | 1 05 06000 01 0000 110 | 1 300 000,0 |
| «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимы куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 07000 01 0000 110 | 46 100,0 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 46 062 667,9 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 39 141 573,9 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 6 915 130,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 5 964,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 10 966,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 8 966,0 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары | 1 07 04000 01 0000 110 | 2 000,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| объектларыннан файдаланган өчен җыемнар | | |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 727 447,0 |
| Граждан хәле актларын теркәү органнары һәм башка вәкаләтле органнар (Россия Федерациясе консуллык учреждениеләреннән тыш) тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләр башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 05000 01 0000 110 | 481,4 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 06000 01 0000 110 | 19 293,2 |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук башка юридик әһәмиятле гамәлләр башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 707 672,4 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 12 601 993,5 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр карамагындагы акцияләр буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 112 200,0 |
| Бюджетлар чараларын урнаштырудан керемнәр | 1 11 02000 00 0000 120 | 2 701 775,3 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 25 032,0 |
| Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 9 672 256,0 |
| Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турындагы килешүләр буенча түләү | 1 11 05300 00 0000 120 | 23 915,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 15 486,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт | 1 11 08000 00 0000 120 | 51 329,2 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар | | |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 273 729,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 111 630,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 66 531,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 95 568,0 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 776 640,0 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 327 139,0 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 449 501,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 25 398,0 |
2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясы белән билгеләнә торган төп характеристикалары (фаразлана торган керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты) закон проектының 1 статьясында китерелә.

Әлеге статья белән шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары турында кушымта раслана.

Закон проектының 2 статьясында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычына, Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычына кагылышлы параметрлар билгеләнә, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына ихтимал гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә Татарстан Республикасы бюджет ассигнованиеләре, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының эчке дәүләт займ программасы раслана.

3 статьяда 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре күләмнәре исәпкә алына. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре төрләре буенча тасвирлама аңлатма язуының 5 – 8 битләрендә бирелә.

Закон проектының 4 статьясында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе Бюджет законнары актларында билгеләнмәгән керемнәрне бүлү нормативлары раслана.

Закон проектының 5 статьясында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына

акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәре билгеләнә.

6 статьяда акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлык җәмгыятьләренең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләренә дивидендлар күләме һәм күрсәтелгән җәмгыятьләрнең чиста табышыннан файдалану мәсьәләләре буенча тавыш бирүгә кагылышлы йөкләмә бирү күздә тотыла.

Моннан тыш, статьяда 2024 елда дәүләт унитар предприятиеләре табышының Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган өлешенең күләме билгеләнә.

7 статья бюджет законнарының база таләпләре нигезендә бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомстволар буенча структурасын, шулай ук бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча, шулай ук чыгымнар төрләре максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне билгели торган кушымталарны раслау турындагы нигезләмәләрне үз эченә ала. 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы бюджетының чыгымнар өлешенең җентекле тасвирламасы аңлатма язуының 9 – 23 битләрендә бирелде.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^{1}$ статьясы нигезендә шулай ук 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме раслана.

8 статья белән, Росия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 2 һәм 7 пунктлары нигезендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр формасындагы грантлар рәвешендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр бирүнең һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре булып тормаучы коммерциясез оешмаларга субсидияләр бирүнең, казна учреждениеләре булып тормаучы коммерциясез оешмаларга грантлар бирүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә хәл ителүе билгеләнелә.

9 статья белән Татарстан Республикасы бюджетына җирле бюджетлар тарафыннан бюджетара субсидияләрне түләү тәртибе җайга салына.

10 статья белән муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүленеше һәм 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары булган кушымта, шулай ук муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие һәм күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечләре билгеләнә.

11 статьяда 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль берәмлекләр арасында бюджетара трансфертларны бүлүдән гыйбарәт булган кушымталар раслана.

12 статья белән 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына түләнергә тиешле иминият кертемнәре һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләме раслана.

13 статьяда 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Юл фондының бюджет ассигнованиеләрен куллану күләме һәм юнәлеше раслана.

14 статьяда 2024 елга, 2025 һәм 2026 план чорында инвестиция салым кредитлары бирүгә җибәрелә торган акчаларның иң чик күләме билгеләнә.

15, 18, 20 статьялар редакцияләре закон текстына ел саен кертелә торган нигезләмәләрне, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыру турында карарлар кабул итмәү, Татарстан Республикасы бюджетын үтәү, җәмәгать килешүләрен төзү шартлары турындагы нигезләмәләрне үз эченә ала.

16 статьяда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән очракларда, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм

башка бюджетара трансфертлар күчерүнең мондый бюджетара трансфертлар бирелә торган финанслашу (финаслар белән тәэмин итү) максатында, җирле бюджетларны алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хәл ителүе билгеләнә.

17 статьяда 2024 елда, 2025 һәм 2026 еллар план чорында федераль бюджеттан бюджетара трансфертларны, «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясеннән кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алучы кушымта раслана.

19 статьяда файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган өлешен, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бюджетара трансфертлар бирүгә, 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы исеменнән юридик затларга товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары буенча субсидияләр түләүгә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты средстволарын алучыларның акчалата йөкләмләләрен түләүгә һәм 2023 елда шул дәүләт контрактлары, акчалата йөкләмәләрне түләү шартлары нигезендә, юридик затларның – субсидия алучыларның акчалата йөкләмәләрен, акчалата йөкләмәләрен түләүгә җибәрү мөмкинлеге күздә тотыла.

21 статьяда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозган өчен норматив хокукый актлар нигезендә табигатьне саклау чараларына җибәрелә дип билгеләнә.

22 статьяда текст нигезләмәсе рәвешендә 2024 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге вакыт аралыгында туктатып тору өчен тәкъдим ителә торган закон актлары исемлеге бирелә.

23 статья Законның 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен күздә тота.

**Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре**

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре республиканың социаль-икътисадый үсешенең макроикътисадый күрсәткечләреннән, салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән, салым салына торган база буенча Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең хисап белешмәләреннән һәм 2023 ел ахырына кадәр Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр керүне бәяләүдән чыгып төзелде.

Бюджет төзегәндә Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Россия Федерациясе Салым кодексына, салымнар һәм җыемнар буенча башка закон актларына кергән үзгәрешләр һәм өстәмәләр исәпкә алынды.

Табышка салымнар, физик затлар кеременә салымнар, акцизлар һәм оешмалар мөлкәтенә салым бюджетның иң күләмле керем чыганаклары булып торып, Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең гомуми суммасының 87 процентын тәшкил итә.

**Оешмалар табышына салым** Татарстан Республикасы бюджетының зур керем чыганагы булып кала. Исәпләүнең нигезенә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча «Табыш» күрсәткеченең алдан фаразланган күләме, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең алдагы чорларда салым салына торган база турында хисап мәгълүматлары, шулай ук 2023 елның узган чорында салымның фактта керүе кабул ителде. Шулай ук республиканың зур һәм уртача оешмаларының 2023 ел ахырына кадәр һәм 2024 – 2026 елларда табышка салымы фаразлары буенча мәгълүматларыннан файдаланылды.

2024 елда табышка салым 112 821,0 млн. сум, 2025 елда – 118 462,1 млн сум, 2026 елда – 125 570,0 млн. сум күләмендә булыр дип фаразлана.

2024 елда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына **физик затлар кеременә салым** 137 524,9 млн. сум күләмендә фаразлана, 2025 елда – 147 673,4 млн. сум, 2026 елда – 158 420,5 млн. сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджетына тиешенчә – 96 447,4 млн. сум, 103 551,3 млн. сум һәм 111 074,4 млн. сум. Салым буенча исәп-хисап Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы фаразлый торган хезмәткә түләү фондына көтелгән салым суммасыннан һәм аның үсеш темпларыннан чыгып башкарылды.

2024 елга Татарстан Республикасы бюджетына **акцизларның** гомуми суммасы 41 439,7 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән алкогольле продукциягә һәм спиртка акцизлар – 10 048,0 млн.сум, сырага акцизлар – 13 306,1 млн. сум, нефть продуктларына акцизлар – 18 035,6 млн. сум, сыек корычка – 50,0 млн. сум күләмендә бәяләнә.

2025 елга акцизларның гомуми суммасы 43 008,9 млн. сум, 2026 елга – 44 477,1 млн. сум күләмендә бәяләнә.

Акцизлар буенча фараз Татарстан Республикасы сыра һәм сыек корыч җитештерүчеләренең акциз продукциясен сату күләмнәренең фаразланган күләменнән, тулаем Россия Федерациясе буенча алкогольле продукция буенча, тулаем Россия Федерациясе буенча нефть продуктлары буенча акцизлы продукция сату күләмнәреннән чыгып, гамәлдәге акцизлар

ставкаларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы өчен бюджетлар дәрәҗәләре арасында акцизларны бүлү өлешләрен һәм акцизларны бүлү нормативларын исәпкә алып төзелде.

**Җыелма керемгә салымнар** фаразы республика бюджетына 2024 елга 17 285,2 млн. сум, 2025 елда – 17 922,8 млн. сум, 2026 елда – 18 585,8 млн. сум күләмендә исәпләнде.

Җыелма керемгә салымнарны исәпләү Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге «Салым салуның гадиләштерелгән системасы» 26.2 бүлеге, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422–ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2022 елның 25 февралендәге 17-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән салым законнары нормалары нигезендә башкарылды.

Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым керемнәре 2024 елда 15 939,1 млн. сум, 2025 елда – 16 576,7 млн. сум, 2026 елда – 17 239,7 млн. сум күләмендә бәяләнә. Салымнар буенча кертемнең артуы салым базасының 2024 – 2026 елларда 104,0% күләмендә инфляция дәрәҗәсенә фаразланган үсешенә бәйле.

Һөнәри керемгә салым кереме 2024 – 2026 елларда 1 300,0 млн. сум күләмендә бәяләнә.

Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым керемнәре 2024 – 2026 елларда 46,1 млн. сум күләмендә бәяләнә.

**Оешмалар мөлкәтенә салым** буенча фараз, төп капиталга инвестицияләр үсеше темпын исәпкә алып, салым хисабы мәгълүматлары нигезендә төзелде.

2024 елда салым суммасы 39 141,6 млн. сум күләмендә булыр дип фаразлана. 2025 елга салым күләме 40 589,8 млн. сум, 2026 елга – 43 187,6 млн. сум күләмендә бәяләнә.

2024 елга **транспорт салымы** керү фаразы 6 915,1 млн. сум, 2025 елга – 7 115,7 млн. сум, 2026 елга – 7 322,0 сум күләмендә бәяләнә. Керемнәрне бәяләгәндә салым хисабы мәгълүматлары, берничә ел эчендә салым керемнәре динамикасы исәпкә алынды. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә транспорт салымы юл фондына фаразланган күләмнәрдә җибәреләчәк.

2024 елга Татарстан Республикасы бюджетына **дәүләт пошлинасы** 727,4 млн. сум, 2025 елда – 733,3 млн. сум, 2026 елда – 731,5 млн. сум булыр дип фаразлана. Юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы керүләренең фаразы Россия Федерациясе Салым кодексының «Дәүләт пошлинасы» $25^3$ бүлеге нормалары һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нормалары нигезендә төзелде.

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына **уен бизнесына** салым буенча кертемнәр фаразы һәр ел саен 12,0 млн. сум күләмендә фаразлана, шулардан Татарстан Республикасы бюджетына – 6,0 млн. сум. Салымны исәпләгәндә салым органнарының уен бизнесына салым буенча хисабыннан файдаланылды.

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы **бюджетына табигый ресурслардан файдаланган өчен салымнар һәм җыемнар** кертү һәр ел саен 11,0 млн. сум күләмендә фаразлана, шул исәптән башка файдалы казылмалар чыгаруга салым – 9,0 млн. сум, хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары объектларыннан файдаланган өчен җыемнар – 2,0 млн.сум.

Татарстан Республикасы бюджетының **салым булмаган керемнәре** фаразы 2024 елга 17 285,0 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән:

- дәүләт милкендә булган мөлкәттән файдалану һәм аны сатудан кергән керемнәр (дәүләт милкендә булган акцияләр пакетларына дивидендлар, бюджет средстволарын урнаштырудан керемнәр, Татарстан Республикасы бюджеты хисабына бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар, сервитут билгеләү турында килешүләр буенча түләү, җир кишәрлекләрен һәм дәүләт мөлкәтен арендалаудан кергән керемнәр, дәүләт унитар предприятиеләре табышының бер өлешен күчерү, милекне ышанычлы идарәгә тапшырудан, дәүләт мөлкәтен сатудан алына акчалар) – 12 627,4 млн. сум;
- 4 657,6 млн. сум күләмендә башка салым булмаган керемнәр (табигый ресурслардан файдаланганда түләүләр, түләүле хезмәт күрсәтүләрдән керемнәр һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләү, административ түләүләр, штраф санкцияләре һәм зыянны каплау, шулай ук башка салым булмаган керемнәр).

2025 елга салым булмаган керемнәр суммасы 16 923,8 млн. сум, 2026 елга – 13 584,4 млн. сум күләмендә фаразлана.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына җирле бюджетлардан күчерелергә

тиешле **бюджетара субсидияләр** 2024 елга 121,8 млн. сум, 2025 елга – 215,8 млн. сум, 2026 елга – 225,0 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

Федераль бюджеттан **кире кайтарылмый торган кертемнәр** Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешендә 2024 елга 51 641,1 млн. сум, 2025 елга – 38 655,3 млн.сум, 2026 елга – 47 679,0 млн. сум, шулардан:

- 2024 елга субсидияләр – 44 909,8 млн. сум, 2025 елга – 31 963,7 млн. сум, 2026 елга – 41 037,2 млн. сум;
- 2024 елга Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр 4 054,4 млн. сум, 2025 елга – 4 403,6 млн. сум, 2026 елга – 4 329,0 млн.сум күләмендә;
- 2024 елга башка бюджетара трансфертлар 2 676,9 млн. сум, 2025 елга – 2 288,0 млн. сум, 2026 елга – 2 312,8 сум.

Бу күләмнәрдә илкүләм проектларның аерым чараларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен алдан ук финанс белән тәэмин итүгә 2023 елда 15 004,6 млн. күләмендә алынган федераль бюджет кредитын 2024 елда каплауга средстволар исәпкә алынган.

«ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясеннән **кире кайтарылмый торган кертемнәр** 2024 елга 87,2 млн. сум күләмендә исәпкә алына.

2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешенең гомуми суммасы 383 929,5 млн. сум, 2025 елга – 387 195,8 млн. сум, 2026 елга – 412 453,8 млн. сум күләмендә фаразлана.

**Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары**

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары гамәлдәге чыгым йөкләмәләреннән, индекс-дефляторлардан, бюджет сәясәтенең төп юнәлешләреннән чыгып формалаштырылды. Әлеге параметрлар нигезендә 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының чыгым өлеше 383 929,5 млн. сум һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына 399 693,8 млн. сум һәм 431 325,5 млн. сум күләмендә формалаштырылды.

2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының чыгым өлешендә 15 004,6 млн. сум күләмендә федераль бюджеттан максатчан средстволар исәпкә алынмаган, алар 2023 елда илкүләм проектларның аерым чараларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен алдан ук финанс белән тәэмин итүгә алынган 15 004,6 млн. сум күләмендәге федераль бюджет кредитын каплауга җибәрелә. Әлеге средстволар закон

проектына «Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтада чагылдырылган.

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары дәүләт программалары нигезендә төзелде. 2024 елдан, федераль дәрәҗәдә кабул ителгән карарлар нигезендә, «Россия Федерациясендә дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 26 май, 2021 ел, № 786 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә күздә тотылган ысуллар һәм принципларга яраклаштыру зарурилыгыннан чыгып, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын яңа идарә системасына күчерү хәл ителәчәк. Моңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм федераль дәүләт программаларын эшләү буенча бердәм ысуллар кулланылачак.

2024 елга һәм шуннан соңгы елларга Татарстан Республикасы программалары «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 30.05.2023 ел, № 655 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, яңа форматта төзелде. Моңа бәйле рәвештә, бюджетта программаларны чагылдыручы чыгымнарның максатчан статьяларының бюджет классификациясе кодлары ачыкланды.

**«Гомумдәүләт мәсьәләләре»** бүлеге буенча 2024 елга чыгымнарның фаразланган күләме 43 015,9 млн. сум, 2025 елга – 43 958,1 млн. сум, 2026 елга – 45 137,4 млн. сум тәшкил итте.

«Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендә түбәндәге төп юнәлешләр буенча чыгымнар исәпкә алынды.

Дәүләт хакимияте органнарын тотуга 2024 елда 3 314,2 млн. сум, 2025 елда – 3 421,0 млн. сум, 2026 елда – 3 532,5 млн. сум карала.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды күләме 2024 елга 13 430,6 млн. сум, 2025 елга – 13 708,1 млн. сум, 2026 елга – 13 996,8 млн. сум дәрәҗәсендә карала.

Әлеге бүлектә оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләүгә 2024 елга 3 720,6 млн. сум, 2025 елга – 3 794,2 млн. сум, 2026 елга – 3 899,2 млн. сум; бюджет өлкәсе учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтен түләүне арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга 2024 елга – 11 110,7 млн.сум, 2025 елга – 11 555,1 млн. сум, 2026 елга – 12 017,3 млн. сум; аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру буенча 2024 елга – 2 647,6 млн. сум, 2025 елга – 2 753,5 млн. сум, 2026 елга – 2 863,6 млн. сум; гражданнарның үзара салымнарын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга 2024 – 2026 елларга һәр ел саен 1 352,1 млн. сум күләмендә бюджет ассигнованиеләре бүлү күздә

тотыла; дәүләт (муниципаль) бюджет һәм автоном учреждениеләренә 2024 – 2026 елларга дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренә (эшләрен башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмләрен үтәү өчен һәр ел саен 2 950,0 млн. сум күләмендә финанс тәэминаты карала.

Фәнгә чыгымнар 2024 елга 1 327,7 млн. сум, 2025 елга – 1 353,1 млн. сум, 2026 елга – 1 376,3 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

«Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендә җирле бюджетларга Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 8 субвенция исәпкә алына.

Әлеге бүлектә федераль бюджеттан 2024 елга 156,5 млн. сум, 2025 елга – 80,4 млн. сум, 2026 елга – 91,4 млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алынды.

**«Милли оборона»** бүлеге буенча чыгымнар 2024 елга 43,6 млн. сум, 2025 елга – 45,1 млн. сум, 2026 елга – 46,6 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

Әлеге средстволар кысаларында мобилизацион әзерлекне тәэмин итү чаралары күздә тотылган.

«**Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге**» бүлеге буенча 2024 елга бюджет ассигнованиеләре 1 695,8 млн. сум, 2025 елга – 1 747,8 млн. сум, 2026 елга – 1 795,9 сум күләмендә планлаштырыла.

«Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлегендә ике дәүләт программасының төп юнәлешләре буенча чыгымнар исәпкә алына:

«Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү»;

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш».

**«Милли икътисад»** бүлеге буенча 2024 елга чыгымнар күләме 102 567,3 млн. сум, 2025 елга – 87 512,6 млн. сум, 2026 елга – 90 877,7 млн. сум күләмендә фаразлана.

Әлеге бүлек буенча 2025 – 2026 елларда чыгымнар күләме кимү аларның «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» бүлекчәсе буенча кимүенә бәйле. Түбән булуның тәфсилле сәбәпләре күрсәтелгән бүлекчәдә китерелгән.

«Милли икътисад» бүлегендә түбәндәге төп юнәлешләр буенча чыгымнар исәпкә алына.

«Гомумикътисадый мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча чыгымнар күләме, Татарстан Республикасының өч дәүләт программасын гамәлгә ашыруга чыгымнарны да кертеп, 2024 елга 733,7 млн. сум, 2025 елга – 709,7 млн. сум, 2026 елга – 710,6 млн. сум тәшкил итте.

Әлеге бүлекчәдә федераль бюджеттан 2024 елга 21,3 млн. сум, 2025 елга – 0,6 млн. млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алынган, шул исәптән:

- чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү;
- хезмәт базарында киренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны, вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыруны тормышка ашыру.

«Минерал-чимал базасын торгызу» бүлекчәсе буенча «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы кысаларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минерал-чимал базасын торгызу чараларына чыгымнар 2024 елда 114,8 млн. сум, 2025 елда – 102,2 млн. сум, 2026 елда – 104,6 млн. сум күләмендә исәпкә алынды.

2025 – 2026 елларга чыгымнар күләме кимү 2024 елда каралган 15,0 млн. сум күләмендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә скважиналарны ревизияләү буенча чараларга чыгымнар күләме кимүгә бәйле.

«Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык» бүлекчәсе буенча 2024 елга чыгымнар 14 718,5 млн. сум, 2025 елга – 11 162,0 млн. сум, 2026 елга – 11 335,5 млн. сум, шул исәптән федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар хисабына чыгымнар 2024 елга 2 694,2 млн. сум, 2025 елга – 2 156,6 млн. сум, 2026 елга – 2 281,9 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

Средстволар «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыруга җибәрелә.

2025 – 2026 елларга чыгымнар күләме кимү түбәндәгеләргә бәйле:

- 2024 елда югарыда күрсәтеп үтелгән дәүләт программасын тормышка ашыруга 3 065,0 млн. сум күләмендә өстәмә чыгымнар кертелүгә;
- чыгымнар күләме 537,6 млн. сумга кимү «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» һәм «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары акселерациясе» федераль проектларын тормышка ашыруга федераль средстволарның 453,1 млн. сум күләмендә чыгымнарның кимүенә, шулай ук агросәнәгать комплексында бәрәңге һәм яшелчә җитештерүгә инвестицион

кредитлар буенча процентларның бер өлешен каплауга һәм бөртекле культуралар җитештерүчеләргә бөртекле культураларны җитештерү һәм сату чыгымнарының бер өлешен 84,5 млн.сумга финанс ягыннан тәэмин итүгә (каплауга) .

«Су хуҗалыгы» бүлекчәсе буенча бюджет ассигнованиеләре «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм куллану» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 2024 елга 591,4 млн.сум, 2025 елга – 268,5 млн. сум, 2026 елга – 211,4 млн. сум карала.

2025 – 2026 елларга чыгым күләмнәренең кимүе 2024 елда табигатьне саклау чараларын тормышка ашыруга 303,7 млн сум күләмендә капиталь характердагы чыгымнарны кертүгә, шулай ук федераль бюджеттан финанслашыла торган гидротехник корылмаларны капиталь ремонтлау чыгымнары күләме кимүгә бәйле.

Әлеге бүлекчә буенча федераль бюджеттан 2024 елга 180,2 млн. сум, 2025 елга – 252,2 млн. сум, 2026 елга – 211,5 млн. сум күләмендә средстволар исәпкә алынган, шул исәптән:

- су мөнәсәбәтләре өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга 2024 елга – 19,0 млн. сум, 2025 елга – 228,7 млн. сум, 2026 елга – 211,5 млн. сум күләмендә;

- су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга 2024 елга – 161,2 млн. сум, 2025 елга – 23,5 млн. сум.

«Урман хуҗалыгы» бүлекчәсе буенча бюджет ассигнованиеләре «Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 2024 елга 785,2 млн. сум, 2025 елга – 752,4 млн. сум, 2026 елга – 777,2 млн. сум карала.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына чыгымнар 2024 елда 619,3 млн. сум, 2025 елга – 563,3 млн. сум, 2026 елга – 578,3 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

Әлеге бүлекчә буенча федераль бюджеттан субвенцияләр исәбенә 2024 елга 165,9 млн. сум, 2025 елга – 189,1 млн. сум, 2026 елга – 198,9 млн. сум күләмендә чыгымнар исәпкә алынган.

2025 – 2026 елларга бюджет ассигнованиеләренең кимүе 2024 елда лесничестволар һәм урман хуҗалыклары биналарын капиталь төзекләндерүгә 70,5 млн. сум күләмендә чыгымнар кертелүгә бәйле.

«Транспорт» бүлекчәсе буенча чыгымнар асылда «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 2024 елга 2 138,4 млн. сум күләмендә, 2025 елга – 2 141,5 млн. сум, 2026 елга – 2 144,7 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

«Юл хуҗалыгы (юллар фондлары)» бүлекчәсе буенча 2024 елга чыгымнар күләме 52 765,6 млн. сум, 2025 елга – 30 041,8 млн. сум, 2026 елга – 30 229,6 млн. сум күләмендә исәпкә алына.

Чыгымнарның иң зур күләме «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасының «Автомобиль юллары челтәрләрен камилләштерү, үстерү һәм саклау» төбәк проектын тормышка ашыруга җибәрелә.

Әлеге бүлекчә буенча 2024 елга 6 312,2 млн. сум, 2025 елга – 452,0 млн. сум, 2026 елга – 69,6 млн. сум федераль бюджеттан средстволар исәпкә алынган, шул исәптән:

- дәүләти-хосусый партнерлык механизмын кулланып гамәлгә ашырыла торган проектлар буенча юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 5 339,5 млн. сум;

- авыл территорияләрендә транспорт инфраструктурасын үстерүгә 2024 елга 972,7 млн. сум, 2025 елга – 452,0 млн. сум, 2026 елга – 69,6 млн. сум.

Чыгымнарның гомуми күләмендә дәүләти-хосусый партнерлык механизмын кулланып гамәлгә ашырыла торган «Шәле (М-7) – «Баулы (М-5)» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск-Әлмәт» автомобиль юлын төзүгә 2024 елга 22 490,3 млн сум, шул исәптән федераль бюджет средстволары хисабына 5 339,5 млн. сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына 17 150,8 млн. сум исәпкә алынды.

Әлеге бүлекчә буенча 2025 – 2026 елларга чыгымнарның кимүе югарыда күрсәтеп үтелгән объектны төзеп бетерүгә, шулай ук авыл территорияләрендә транспорт инфраструктурасын үстерүгә федераль бюджеттан керүче средстволарның кимүенә бәйле.

«Элемтә һәм информатика» бүлекчәсе буенча чыгымнар 2024 елда 1 636,2 млн. сум, шул исәптән федераль бюджеттан мәгълүмат технологияләре өлкәсендә региональ проектларга ярдәм итүгә 2,6 млн. сум, 2025 елда – 1 644,6 млн. сум, 2026 елда – 1 651,0 млн. сум тәшкил итә һәм нигездә «Цифрлы Татарстан» дәүләт программасы кысаларында карала.

«Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча Татарстан Республикасы бюджеты проектында чыгымнар күләме 2024 елга 29 083,5 млн. сум, 2025 елга – 40 689,9 млн. сум, 2026 елга – 43 713,1 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

2025 – 2026 елларда чыгымнар күләме арту федераль бюджеттан бюджетара трансфертларның тигез бүленмәве белән аңлатыла.

Әлеге бүлекчә буенча акчаларны нигездә Татарстан Республикасының 11 дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерү планлаштырыла. Аларның расшифровкасы закон проектына 7 нче кушымтада китерелгән.

Чыгымнар составында»Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль парклары («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктурасы һәм «Этилен-600» инфраструктурасы объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә 2024 елга – 22 190,0 млн. сум, 2025 елга – 34 380,0 млн. сум, 2026 елга – 36 960,0 млн. сум, шул исәптән федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар хисабына 2024 елга – 12 910,0 млн. сум, 2025 елга – 25 468,0 млн. сум, 2026 елга – 34 382,0 млн. сум күләмендә күздә тотылган.

Шулай ук әлеге бүлекчә буенча федераль бюджеттан 2024 елга алыначак 467,4 млн. сум, 2025 елга – 126,2 млн. сум, 2026 елга – 469,3 млн. сум күздә тотылган, шул исәптән:

- 2024 елга кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме 131,9 млн. сум;

- 2024 елга компримировкаланган табигый газның ягулык салу инфраструктурасын үстерү проектларын гамәлгә ашыру 21,6 млн. сум;

- 2024 елга табигый газны мотор ягулыгы сыйфатында файдалану өчен автомобиль техникасын яңадан җиһазлау проектларын гамәлгә ашыруга 27,6 млн. сум, 2026 елга – 23,3 млн. сум;

- 2024 елга сәнәгатьне үстерүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыруга 50,4 млн. сум;

- 2024 елга комплекслы кадастр эшләрен үткәрү чараларын гамәлгә ашыруга 10,0 млн. сум, 2025 елга – 24,4 млн. сум, 2026 елга – 98,6 млн. сум;

- шәһәр агломерацияләрендә юл хәрәкәтенә идарә итү процессларын автоматлаштыруны күздә тотучы интеллектуаль транспорт системаларын кертү, халкы 300 мең кешедән артык булган шәһәрләрне кертеп, 2024 елга – 115,6 млн. сум, 2025 елга – 101,8 млн. сум, 2026 елга – 347,4 млн. сум күләмендә;

- инвестицион проектларны тормышка ашыруда капиталь булмаган модульле средстволар булдыруга 2024 елда 110,3 млн. сум күләмендә.

**«Торак-коммуналь хуҗалык»** бүлеге буенча 2024 елга чыгымнарның фаразланган күләме 11 060,0 млн. сум тәшкил итте, 2025 елга – 11 228,5 млн. сум, 2026 елга – 11 581,4 млн. сум, асылда «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» һәм «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» дәүләт программалары кысаларында.

**«Әйләнә-тирә мохитне саклау»** бүлеге буенча бюджет ассигнованиеләре 2024 елга 3 164,1 млн сум, 2025 елга – 377,5 млн. сум, 2026 елга – 379,9 млн. сум күләмендә, «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм куллану» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга карала.

Әлеге бүлектә нигездә экологик юнәлешле чараларга федераль бюджеттан керүче акчалар 2024 елга 2 257,9 млн сум күләмендә исәпкә алынган.

2025 һәм 2026 елларга средстволарның кимүе «Экология» илкүләм проекты составына керүче «Чиста ил» һәм «Иделне чистарту» федераль проектларын тормышка ашыруга федераль средстволарның кимүенә бәйле.

**«Мәгариф»** бүлеге буенча 2024 елга чыгымнарның фаразланган күләме 80 224,3 млн. сум тәшкил итә, 2025 елга – 94 733,0 млн. сум, 2026 елга – 109 351,2 млн. сум.

2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының үсеше сценарий шартлары буенча агымдагы чыгымнарны индексацияләү, 2024 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру, шулай ук Россия Федерациясе Президентының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакын тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү буенча «май ае» Указларын үтәүгә акчаларны планлаштыру белән аңлатыла. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы белем бирү оешмалары тарафыннан дәүләт заданиеләрен үтәүгә чыгымнар һәм мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә субвенция күләме арта.

Мәгариф оешмалары эшчәнлеген тәэмин итүгә һәм мәгариф өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Шулай ук «Мәгариф» бүлегендә мәгариф өлкәсендә төбәк проектларын һәм процесслы чаралар комплексын үз эченә алган 12 дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга акчалар карала.

Әлеге бүлек буенча федераль бюджеттан 2024 елга 4 776,5 млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алына, 2025 елга – 4 111,5 млн. сум, 2026 елга – 4 866,0 млн. сум, аларны нигездә түбәндәге чараларга җибәрергә планлаштырыла:

- мәгариф оешмалары инфраструктурасын модернизацияләүгә, шул исәптән матди-техник базаны яңартуга;

- дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү;

- дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның кайнар ризык белән бушлай туклануын оештыруга.

- «Яшьләр өчен төбәк» Россия Федерациясе төбәкләрендә яшьләр сәясәтен комплекслы үстерү программасын тормышка ашыруга.

**«Мәдәният, кинематография»** бүлеге буенча 2024 елга бюджет ассигнованиеләре 9 668,1 млн. сум, 2025 елга – 11 035,2 млн. сум, 2026 елга – 12 994,3 млн. сум күләмендә карала. Бу күләмгә федераль бюджеттан 2024 елга 254,8 млн. сум, 2025 елга – 10,4 млн. сум, 2026 елга – 112,5 млн сум күләмендә бюджетара трансфертлар керә.

2024 һәм 2025 елларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының үсүе сценарий шартлары буенча агымдагы чыгымнарны индексацияләү, 2024 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру, шулай ук Россия Федерациясе Президентының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакының тиешле дәрәҗәсен тәэмин итү буенча «май ае» Указларын үтәүгә акчаларны планлаштыру белән аңлатыла.

Мәдәният учреждениеләрен тоту, мәдәният һәм кинематография өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру чыгымнары «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы кысаларында планлаштырылган. Шулай ук «Мәдәният, кинематография» бүлегендә 2024 – 2026 елларда 7 дәүләт программасын гамәлгә ашыруга чыгымнар исәпкә алынган.

**«Сәламәтлек саклау»** бүлеге буенча бюджет ассигнованиеләре 2024 елга 38 773,4 млн. сум, 2025 елга – 40 696,5 млн. сум, 2026 елга – 41 537,0 млн. млн. сум күләмендә планлаштырылган.

2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының үсүе сценарий шартлары буенча агымдагы чыгымнарны индексацияләү, 2024 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру, шулай ук Россия Федерациясе Президентының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакын тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү буенча «май ае» Указларын үтәүгә акчаларны планлаштыру белән аңлатыла.

Татарстан Республикасы медицина оешмалары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру, сәламәтлек саклау объектларына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт нигездә «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Әлеге бүлек буенча 2024 елга федераль бюджеттан 1 182,4 млн. сум, 2025 елга – 763,7 млн. сум, 2026 елга – 754,1 млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алына.

**«Социаль сәясәт»** бүлеге буенча 2024 елга 60 117,4 млн. сум күләмендә бюджет ассигнованиеләре исәпкә алына, 2025 елга – 63 700,4 млн. сум, 2026 елга – 67 154,0 млн. сум.

2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының үсүе сценарий шартлары буенча агымдагы чыгымнарны индексацияләү, 2024 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру, шулай ук Россия Федерациясе Президентының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакын тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү буенча «май ае» Указларын үтәүгә акчаларны планлаштыру белән аңлатыла.

Әлеге бүлек буенча «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын түбәндәге төп юнәлешләр буенча финанслау исәпкә алынды:

- халыкны социаль тәэмин итү (законнарда каралган һәм инфляциягә карап индексацияләнгән барлык социаль түләүләр планлаштырылган);
- пенсия белән тәэмин итү;
- халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Күздә тотылган акчалар социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең тиешенчә эшләвен тулысынча тәэмин итәчәк.

«Социаль сәясәт» бүлеге буенча 2024 елга гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча федераль бюджеттан 3 912,1 млн. сум, 2025 елга – 4 031,9 млн. сум, 2026 елга – 4 139,2 млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алына.

«**Физик культура һәм спорт**» бүлеге буенча бюджет ассигнованиеләре 2024 елга 4 100,7 млн. сум, 2025 елга – 6 402,4 млн. сум, 2026 елга – 6 502,8 млн. сум күләмендә карала.

Югарыда атап үтелгән акчалар хисабына учреждениеләрне карап тоту, физик культура һәм спорт өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру, физик культура һәм спорт объектларын капиталь ремонтлау гамәлгә ашырылачак.

Әлеге бүлектә федераль бюджеттан 2024 елга 54,4 млн. сум, 2025 елга – 1 012,0 млн. сум, 2026 елга – 102,0 млн. сум күләмендә бюджетара трансфертлар исәпкә алына.

**«Массакүләм мәгълүмат чаралары»** бүлеге буенча 2024 елга бюджет ассигнованиеләре 1 735,1 млн. сум күләмендә, 2025 елга 1 681,9 млн. сум, 2026 елга – 1 685,5 млн. сум күләмендә планлаштырылган.

2025 – 2026 елларда чыгымнар күләме кимү 2025 елда берничә чараның тәмамлануы белән, шулай ук аерым дәүләт программалары чараларының билгеле бер вакыт аралыкларында уздырылуы белән аңлатыла.

«**Дәүләт (муниципаль) бурычына хезмәт күрсәтү**» бүлеге буенча 2024 елга бурыч йөкләмәләре буенча процент түләүләрен 857,2 млн. сум, 2025 елга – 814,4 млн. сум, 2026 елга – 756,5 млн. сум күләмендә түләү карала.

**«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар»** бүлеге буенча муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр һәм гомуми характердагы башка бюджетара трансфертлар чагылдырыла.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджетара мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон нигезендә формалаштырылган.

Татарстан Республикасында 956 җирле бюджет: 2 шәһәр округы, 43 муниципаль район һәм 911 җирлек бюджеты бар.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштыру алдыннан муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән башлангыч күрсәткечләрне Татарстан

Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпләү өчен җирле бюджетларга төгәлләштерү һәм килештерү булды.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда бердәм гомумреспублика алымнары һәм 2023 елның база чыгымнарына дефлятор-коэффициентлар исәпкә алынды.

Чыгымнарның бюджет классификациясе нигезендә максатчан бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының тиешле функциональ бүлекләрендә һәм бүлекчәләрендә чагылдырылды.

Муниципаль берәмлекләр бюджетларына гомуми характердагы финанс ярдәме 2024 елга 47 535,3 млн. сум күләмендә карала, шул исәптән муниципаль районнар, шәһәр округлары бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең бер өлешен алмаштыручы өстәмә нормативлар буенча күчерелгән акча күләме – 20 628,7 млн. сум; 2025 елга – 45 261,4 млн. сум күләмендә, шул исәптән югарыда күрсәтелгән физик затлар керемнәренә өстәмә нормативлар буенча салымнан – 22 151,0 млн. сум; 2026 елга 44 288,4 млн сум күләмендә акча күчерү күздә тотыла, шул исәптән югарыда күрсәтелгән өстәмә нормативлар буенча физик затлар керемнәренә салымнан 23 763,1 млн. сум күләмендә акча күчерү күздә тотыла.

2025 һәм 2026 елларда финанс ярдәме күләмен киметү, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә, сценарий шартлары буенча чыгымнарның үсеш темпы белән чагыштырганда, җирле бюджетлар керемнәренең фараздагы еллык үсеш темпларының зуррак булуы белән аңлатыла.

Әлеге финанс ярдәме күләме, бюджетларны формалаштыруның сценарий шартларында, 2024 – 2026 елларга җирле бюджетларның баланслылыгын тулысынча тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк.

Дотацияләр, субвенцияләр һәм субсидияләр закон проектының тиешле статьяларында һәм аңа кушымталарда чагылдырылган.

Закон проектының 10 статьясында **муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр** күләме расланган.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^2$ статьясы нигезендә бирелү күздә тотыла. Дотация күләмнәре, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тиешенчә тәэмин ителешен тигезләү критериенә ирешү зарурлыгыннан чыгып, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына $2^1$ һәм 5 нче кушымталар белән расланган методикалар нигезендә билгеләнде.

Әлеге статьяда муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджеттан тиешенчә тәэмин ителешен тигезләү критерие һәм күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечләре билгеләнгән.

10 нчы кушымта белән **муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр** бүлү һәм аларны алыштыручы физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары расланды.

Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан **җирле бюджетларга субсидияләр** ике кушымтада чагылдырыла.

11 нче кушымта белән муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджеттан тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү буенча муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу һәм муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертларның башка формаларын бирү максатларында муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр бүлү расланды.

12 нче кушымта белән муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау, тәрбияләү һәм тоту буенча муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатында муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бүлү расланды.

Шулай ук закон проекты белән җирле үзидарә органнарының мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар каралган.

17 нче кушымта белән **Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр** бүленгән.

«Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына, тиешле субвенцияләр бирүгә шушы дәүләт вәкаләтләре бирелгән.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләрнең гомуми күләме «Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган методика нигезендә шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийләренә ирешү зарурлыгына карап билгеләнде.

Моннан тыш, бүлектә **муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар** карала.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 28.03.2019 ел, № 233 карарын гамәлгә ашыру максатларында бүлектә 2024 – 2026 елларга муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына һәр ел саен 428,9 млн. сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар карала.

**Шартлыча расланган (расланган) чыгымнар** күләме планда каралган чорның беренче елына Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә, икенче елында Татарстан Респу бликасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләменнән кимендә 5 проценты күләмендә билгеләнә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар хисабына күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын исәпкә алмыйча).

Закон проектында шартлыча расланган чыгымнар күләме 2025 елга 12 650,0 млн. сум, 2026 елга – 21 000,0 млн. сум күләмендә исәпкә алына, бу Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми суммасының 3,5 процентын һәм 5,5 процентын (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар хисабына күздә тотылган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча) тәшкил итә.

**Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы** 2025 елда 12 498,0 млн. сум, 2026 елда – 18 871,7 млн. сум күләмендә планлаштырыла.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре һәм чыгымнары – бертигез дәрәҗәдә.

Шуның белән бергә, 2024 елда Татарстан Республикасында илкүләм проектларның аерым чараларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен алдан ук финанс белән тәэмин итү өчен 2023 елда 15 004,6 млн. сум күләмендә алынган федераль бюджет кредитын каплау планлаштырыла. Бу каплау 2024 елга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларында чагылдырылган. Әлеге бюджет кредитын каплау чыганагы булып керем өлешендә чагылдырылган, 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетына

бюджетара трансфертлар рәвешендә 15 004,6 млн сум күләмендә федераль бюджеттан алыначак средстволар тора.

Моңа бәйле рәвештә, үз средстволары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы 15 004,6 млн. сум тәшкил итә.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы**
**законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип тану,**
**гамәлдә булуын туктатып тору, үзгәрешләр кертү турында яисә**
**яңа кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнар**
**һәм башка норматив хокукый актлар**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип тану, үзгәрешләр кертү турында яисә яңа Татарстан Республикасы законнарын кабул итүне таләп итми.

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын кабул итүне таләп итә:

- Татарстан Республикасының дәүләт программаларын раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында;

- «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы бюджеты турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә әзерләнде.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2024 елга 383 929 489,4 мең сум, 2025 елга 387 195 794,7 мең сум һәм 2026 елга 412 453 816,0 мең сум күләмендә тәкъдим ителә.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2024 елга 383 929 489,4 мең сум, 2025 елга 399 693 755,0 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар – 12 650 000,0 мең сум, һәм 2026 елга 431 325 559,3 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар – 21 000 000,0 мең сум итеп тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы 2025 елда – 12 497 960,3 мең сум, 2026 елда – 18 871 743,3 мең сум.

Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча җыелма сальдо 2025 елда – 12 497 960,3 мең сум, 2026 елда – 18 871 743,3 мең сум.

Шулай итеп, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының закон проекты белән каралган күрсәткечләре нисбәтләнгән.